КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1272

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында» 2016 ел, 31 март, 191 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында» 2016 ел, 31 март, 191 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 25 декабрь, 1031 нче; 2018 ел, 26 апрель, 294 нче; 2018 ел, 11 июнь, 460 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы белән» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның беренче, икенче һәм ундүртенче абзацларында «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгының» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгының» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктның унҗиденче һәм унсигезенче абзацларында тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен тиешле килешләрдәге «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р.Фазлыевага йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия составында:

комиссия составыннан Р.М.Гарифуллинны, Л.О.Сулиманы чыгарырга;

В.А.Леонов вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының спорт министры»;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Асадуллина Алсу Мөниб кызын | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасарын |
| Биканова Эльвира Рәис кызын | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары ярдәмчесен |
| Зарипов Раушан Булат улын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенең физик культура һәм спортны үстерү мәсьәләләре бүлекчәсе мөдирен |
| Садыйков Ринат Наил улын | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре буенча министры урынбасарын |
| Фәттахов Дамир Илдус улын | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре буенча министрын, комиссия рәисе урынбасарын; |

әлеге карар белән расланган Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия турыда нигезләмәне һәм Балалар һәм яшьләр ялын оештыруга Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәләләр).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин